СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**КАРАР**

**« 19 » октябрь 2017 ел** **№ 1**

**Төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Иске Чүриле авыл җирлеге Уставы, Иске Чүриле авыл җирлегендә, Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2009 елның 29 октябрендәге 21 номерлы карары белән (2012 елның 06 февралендәге 12 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Иске Чүриле авыл җирлегендә халык хокукларын муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Иске Чүриле авыл җирлегенең Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларын 07.11.2017 елга билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны Иске Чүриле авыл җирлеге Советының «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча 10.00 сәгатьтә ТР, Арча муниципаль районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урамы, 52 адресы буенча үткәрергә.

3. Иске Чүриле авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә тәкъдим ителә торган үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, искәрмәләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалары язмача рәвештә 16 сәгатькә кадәр җибәрелә дип билгеләргә. 07.11.2017 елга кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР, Арча муниципаль районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 й., тел.88436657-3-48.

4. Әлеге карарны һәм Иске Чүриле авыл җирлеге Советының «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карары проектын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина

СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012646